# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге составына керүче Бохарай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**22.11.2019** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 12 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Бохарай авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру;
- санкцияләнмәгән чүплекләрдән каты көнкүреш калдыкларын чыгару;
- волейбол сеткасы һәм туп сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю;
- зиратны төзекләндерү (мәгълүмат стенды һәм эскәмия сатып алу һәм урнаштыру);
- һәйкәлне төзекләндерү (коймасын буяу);
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 346 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 253 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 174 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 79 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Бохарай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Бохарай авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру;
- санкцияләнмәгән чүплекләрдән каты көнкүреш калдыкларын чыгару;

- волейбол сеткасы һәм туп сатып алу;
- торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю;
- зиратны төзекләндерү (мәгълүмат стенды һәм эскәмия сатып алу һәм урнаштыру);
- һәйкәлне төзекләндерү (коймасын буяу);
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру.» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бохарай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Нуриев